**Муниципальное бюджетное учреждение**
**дополнительного образования «Центр детского творчества»**
**Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан**

| **«Рассмотрено»** | **«Согласовано»** | **«Утверждаю»** |
| --- | --- | --- |
| на педагогическом совете МБУ ДО «ЦДТ» протокол № 1 от «14» августа 2020 г. | Зам. директора по УВР МБУ ДО «ЦДТ» ___________И.Р. Пузырьков «14» августа 2020 г. | Директор МБУ ДО «ЦДТ» ___________ Р.Г. Иминова Приказ № ___ от «14» _______ 2020 г. |

# Рабочая программа по историческому краеведению

возраст обучающихся 6-18 лет
срок реализации 3 года

Автор-составитель:
педагог дополнительного образования
Габдрахманов И.Г.

с. Верхний Тимерлек
2020 год

# Аңлатмалы кереш.

Туган якны өйрәнү һәм саклау һәрбер гражданның изге бурычы. Россия Федерациясе Конституциясенең 44 статьясының 3 өлешендә әлеге дәүләттә яшәүче кешенең тарихи һәм мәдәни нәселне сакларга тиешлеге әйтелә. Туган якны өйрәнүгә аның табигате, тарихы, гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте керә. Бу хезмәттә без туган як тарихын өйрәнүгә тукталып китербез. Аның максатын һәм бурычларын ачыклап, нинди юнәлешләрдә һәм формаларда кирәкле дәрәҗәдә эшләргә кирәклеген ачыкларга тырышырбыз.

Туган якны өйрәнүнең беренче хезмәтләре XV-XVI гасырларга карый,ул чордагы елъязмаларда чагылыш таба. XVIII гасырның уртасында Россия өлкәләрен сүрәтләгән беренче хезмәтләр күренә. Шул ук гасырның икенче яртысында бу өлкәдә уңай күренешләр күзәтелә. 1777 елда, өлкә реформасы үткәрелү сәбәпле, Сенат бөтен губерналарның топографик сүрәтләнешен эшләргә кушып указ бирә. Туган якны өйрәнүдә М.В.Ломоносовның да роле бик зур. Россиянең беренче географик атласын эшләгән вакытта ул бөтен губерналарга махсус анкета җибәрә.Анда һәр өлкә буенча тарих һәм халык яшәеше, табигый байлыклар буенча сораулар кергән була. Россиядә туган якны өйрәнү үсешендә ике юнәлеш билгеләнә: фәнни һәм укыту. 1918 елда РСФСРның бердәм хезмәт мәктәпләренең нигезләмәсе кабул ителә. Туган якны өйрәнүдә төп рольне укучылар уйнарга тиеш була. Туган якны өйрәнү белән галимнәр белән берлектә укучылар шөгыльләнә ала. Тикмәгә генә инде, соңрак, академик Д.С.Лихачев болай дип билгеләп үтми: ” Бу (туган якны өйрәнү) фәннең массакүләм төре: материаллар җыюда зур галимнәр белән янәшә укучылар да эшли.”

Яңа Россия чорында туган якны өйрәнү гомүм дәүләт күренешенә әверелде. 1990 елның апрелендә Россия туган якны өйрәнүчеләр союзы төзелә. Аның тарафыннан комплекслы программа кабул ителде. Ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- Теория һәм туган якны өйрәнү фәне тарихы;
- Россиянең юкка чыккан һәйкәлләре;
- Елъязмалар;
- Россиянең мәдәни учаклары;
- Күренекле якташлар;
- Мәктәптә туган якны өйрәнү;
- Туган якны өйрәнү музейлары.

Бу хезмәттә төп игътибар соңгы икесенә бирелер.

Мәктәпләрдә туган як тарихын өйрәнү нык үзгәрешләр кичерде. Болар барысыда яхшы якка. Әлеге уңай тенденция РФ нең “Мәгариф турында” законы нигезендә мәктәпләрдә милли-региональ компонент кертү белән бәйле. Мәктәпләрдә туган як тарихын өйрәнүгә бик зур игътибар бирелә башлады. Аны өйрәнү буенча өч биеклекне алырга мөмкин:

1) Укучыларның әзер материалны өйрәнүе.

Бәхеткә каршы, безнең республикада Татарстан һәм татар халкы тарихы исемле яңа фән кертелде. Аның дәресләрендә балалар туган өлкә

тарихы буенча теоретик белем алалар. Бу процесста укытучы сөйләве төп урынны алып тора.

6-8 сыйныфларда укучылар елына 10 сәгать хисабыннан Татарстан тарихы исемле фән белән танышалар. 6 сыйныфта республика тарихы иң борынгы заманнардан XVI гасырга кадәр, 7 сыйныфта XVI-XVIII гасырлар, 8 сыйныфта XIX гасыр өйрәнелә. 9-11 сыйныфларда атнасына бер сәгатьтән исәпләнеп Татарстан һәм татар халкы тарихы исемле фән кертелә. 9 сыйныфта XX гасыр өйрәнелсә, 10 сыйныфта икенче концентр башлана, ягъни яңабаштан – борынгы заманнардан алып XIII гасырга кадәр тарих өйрәнелә, ә 11 сыйныфта инде XIX-XX гасырларга игътибар бирелә.

2) Мөстәкыйль белем алу биеклеге.

Бу вакытта укучылар дәреслекләрдән тыш матур әдәбият, матбугат, музей материаллары буенча мәгълүмат алалар. Соңгы елларда мәктәпләр интернет челтәренә тоташтырылып, яңа информация чыганагы алдылар.

3) Әлеге биеклектә укучылар үзләре тарихны өйрәнәләр, фән белән мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнәләр. Бу беренче чиратта түгәрәкләргә карый.

Бу биеклекләргә ирешү җитәкченең төп бурычы. Тулысы белән 3 биеклектә хезмәт башкарылган очракта гына эффектлы эшләргә мөмкин. Шул вакытта гына укучы кирәкле белем һәм тәрбия ала. Аларга иң беренче чиратта тарих ул-кешеләр тарихы икәнлеген аңлатырга кирәк, ә аның тамырлары гаилә тарихына китә. Атаклы белгеч А.Е.Сейненский туган як тарихын өйрәнүне төрле концентрларга бүлә.

1.Минем гаилә.Шәҗәрә.

2.Туган мәктәп.Аның тарихы һәм традицияләре.

3.Авыл(шәһәр): элеккесе, хәзергесе, киләчәге.

4.Район тарихы.

5.Өлкә тарихы.

Бу концентрлар бербөтенне тәшкил итәләр, алар арасында аерма томанлы гына. Мисал өчен, шәҗәрәне өйрәнгән вакытта укучы мәктәп, авыл, район, өлкә тарихына мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта, киресенчә, гомуми тарихны өйрәнгәндә һәрбер гаиләнең дәүләт тарихына катнашы бар икәнлеге ачыклана.

Дөньяда кешелек үсеп бару юнәлешендә хәрәкәт итә, кечедән олыга таба күтәреләбез. Икенче төрле әйткәндә, җиңелдән авырракка. Туган як тарихын өйрәнгән вакытта да укучылар билгеле булган вакыйгалардан, билгесез булганнарны ачырга өйрәнергә тиештер дип уйлыйм.

Туган як тарихын өйрәнгәндә нәрсәләргә игътибар итергә икән соң ?

1. Гуманлы белем бирү. Ягъни, нинди дә булса эшчәнлектә төп урынны аерым бер кеше алып торырга тиеш. Кешелеклелек, әхлаклылык-иң беренче алга куелган бурыч. Шунысын әйтеп китергә кирәк, атаклы шәхесләр белән беррәттән гади якташлар тарихы да зур урын алырга хокуклы.
2. Аерым бер социаль төркемнәр өйрәнелергә тиешле.

3. Шул төбәктәге төрле милләтләрнең тарихына, мәдәниятенә тигез рәвештә игътибар бирергә кирәк.
4. Билгеле бер төбәк кешеләренең башка өлкәләр белән элемтәләрен барларга.
5. Дин тарихы.

Туган якны өйрәнүнең оештыру формалары:

1.Җирле материалларны Россия һәм республика тарихын өйрәнгән дәресләрдә куллану.
2.Гади мәктәпләрдә тирәнтен гуманитар фән өйрәнү.
3.Факультатив курслар.
4.Өстәмә белем бирү берләшмәләре(түгәрәкләр)

Соңгысы буенча программаны тормышка ашырганда түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

1.Методик

--туган як тарихы буенча системалы материаллар;

--эзтабарлык эше буенча бөтен методикаларны белү(библиотека, архив, экспозиция һәм экскурсия эшен белү кирәк);

--укучыларга туган як тарихы тематикасы буенча булган китап фондларын һәм интернетны файдаланырга өйрәтү.

2.Дидактик.

Дәресләрне үткәрү өчен :

--туган як тарихы буенча булган документларның копиясенең булуы;

--игътибар белән якыннан өйрәнер өчен көнкүреш әйберләренең берничә экземплярын булдыру;

--плакатлар, карталар, схемалар ясарга;

--якташларны сөйләтеп җыйган видео-аудио материаллар кирәк.

3.Кадр.

Түгәрәк җитәкчесе түбәндәгеләрне белергә тиешле:

--яшь үзенчәлекләренә карап, эшчәнлек өчен төп максат һәм бурычларны билгеләү, аларны тормышка ашыру;

--еллык планнарны төзи белергә, сөйләү сәнгатенә ия булу;

--укучыларның белемнәрен анализларга, комментарий ясарга һәм бәя бирә белү;

--укучылардан җәмгыять үсешенең закончалыкларын һәм законнарны белүне таләп итү;

--түгәрәктә йөрүчеләрне документлар, аларның копияләре, язма һәм басма текстлар белән эшләргә өйрәтү;

--танып белү эшчәнлеген активлаштыру, укучыларны иҗади күзалларга өйрәтү;

--мөстәкыйль рәвештә укучыларны төрле максатларга ирешүгә этәрү;

--тәрбияләнүче балаларны рефератлар һәм докладлар белән чыгыш ясарга өйрәтү;

--экскурсияләр үткәрергә өйрәтү;

--балалар өчен экскурсияләр оештыру;

--музей эшен оештыра белү;

--эзтабарларны төрле конкурсларга әзерләү.

4.Материаль-техник

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәгеләр кирәк:

--диапроектор;

--фотоаппарат;

--магнитофон;

--телевизор һәм видеомагнитофон;

--интернеттан файдалану һәм документларны язу өчен компьтер;

--видеокамера;

--папкалар, фотоальбомнар һәм канцелярия кирәк-яраклары;

--китаплар фонды.

Туган якны тарихын өйрәнүне III этапка (елга) бүлергә мөмкин. Үземнең тәҗрибә буенча һәрбер ел эшчәнлеге һәм якынча программа белән таныштырып үтәсем килә. Бу эшчәнлек 9-11 сыйныфлар өчен испләнгән.

Беренче елны түгәрәккә йөрүчеләр мәктәп эчендә генә булган материалларга таянып, үз хезмәтләрен гаилә, урам, мәктәп, авыл тарихын өйрәнүгә багышлыйлар. Музейда экскурсоводлар әзерләнә.

Икенче елны инде, балалар игътибарны район тарихына юнәлтәләр. Бу этапта иң кызыклысы башлана да инде. Туган як тарихын өйрәнүчеләр авылдан чыгып китеп район үзәк музеенда, сайлап алып берничә авыл музеенда экскурсиядә булалар, тарихи урыннар һәм һәйкәлләр белән танышалар. Мисал өчен, Югары Тегермәнлек эзтабарлары Балык бистәсе район үзәге музеенда, Геройлар аллеясында, Кадыйр Сибгатуллин музеенда, “Авыл офыклары” газетасы редакциясендә, типографиядә экскурсиядә булып туган як тарихы белән танышалар. Шул ук елны Котлы Бөкәш авылы музеенда булып, борынгы Чаллы шәһәрчеге белән танышалар.

Өченче елда туган як тарихы комплекслы өйрәнелә, зур игътибар республика тарихына бирелә. Борынгы башкалаларыбыз Биләр һәм Болгар шәһәрләре урыннарына, хәзергесе - Казанга барып кайту өченче этапны тәмамлый.

Һәрбер берләшмә җитәкчесе ул, әлбәттә, борынгылар әйтмешли ”юрганына карап аяк суза”. 2-3 этапларда булган экскурсияләр зур финанс сорый. Мәктәпнең мөмкинлеге булмаган очракта, бу эшкә ата-аналарны тартырга кирәк. Алар белән даими элемтәдә торып, бергәләп балаларга патриотик тәрбия сеңдерергә тырышырга тиешлебез.

Туган як тарихын өйрәнү үзәге булып музей тора. Татар-мөселман авылларында мәчет рухи үзәк булса, мәктәптә ул, әлбәттә, туган якны өйрәнүче музей булыр. Шул ук вакытта музей ул - укучыларга патриотик тәрбия бирү үзәге дә. Югарыда әйтелгәннәр буенча, без туган як тарихын өйрәнүнең башлангыч чорын икегә бүлә алабыз.

I.Җирле туган як белән бәйле материаллар җыю.

II.Музей оештыру.

Соңгы дистә елда музейлар саны арткannan-арта. Россия Федерациясенең фән һәм мәгариф министрлыгы мәгълүматы буенча илдә 5850 мәктәп музее испләнә. Шуларның өчтән ике өлешен тарихи музейлар тәшкил итә.Алар

төрле юнәлешләрдә эшлиләр: хәрби-патриотик, авыл, шәһәр, өлкә тарихы, якташларның эшчәнлеге,гаилә династияләре, туган мәктәп, тарих-этнография, археология.

Туган як тарихын өйрәнүчеләрнең бурычы – музей оештыру. Ләкин моның белән генә эш бетми әлбәттә. Спортсменнар “ 1 урынны алу аны саклап калудан җиңелрәк” дип әйткән шикелле, музей ачылганнан соң, әле аның эшчәнлеген һәрдаим рәвештә тәэмин итәргә кирәк. Музей оешканчыга кадәр укучылар җитәкче белән берлектә туган як тарихы белән шөгыльләнсәләр, музей ачылганнан соң бу эшчәнлек дәвам итеп, әле шуның өстенә музейда да эш алып барыла (экскурсияләр үткәрелә, чыгышлар ясала һ.б.). Ягъни музей ачылганнан соң туган як тарихын өйрәнүчеләр икеләтә йөк алып баралар булып чыга. Кызганычка каршы күп кенә мәктәпләрдә ачылган музейлар формаль рәвештә генә яши. Аның материаллары укыту-тәрбия эшендә актив кулланырга мөмкин булса да, педагогик коллектив моңа салкын караган очраклар бар.

Безнең Югары Тегермәнлек урта мәктәбендә көчле музей эшли. 4 дистә ел инде әлеге уку йортында зур эзтабарлык эше алып барыла. 30 ел элек ачылган музей оештыруда хәзерге директор М.М.Мостафинның хезмәте бик зур. Шушы дәвердә җыелган материалларны ул киләчәк буын өчен туплады. Хәзерге көндә дә тарихи учак сүнмичә януын дәвам итә.

Хәзерге вакытта мәктәптә туган як тарихын өйрәнүдә тиешле дәрәҗәдә эшләү өчен укытучының югары профессиональ белгеч булуы кирәк. Ул иң беренче чиратта локаль булган тарихны, чыганаклар, һәйкәлләрне белергә тиеш. Шул ук вакытта балаларны тарту өче чын энтузиаст булу кирәк. Бары тик туган ягын яраткан кеше генә укучыларга патриотик тәрбия бирә ала..Эшчәнлек вакытында өч максат алга куела:

1.Укучыларда тирә-юнь дөньяда лаеклы урын таба алырлык күпкырлы шәхесләр тәрбияләү.

2.Үз туган як тарихын Россия тарихы контекстында өйрәнү. Уку процессында эзләнү, музей-оештыру күнекмәләрен булдыру.

3.Укучыларды гражданлык һәм патриотизм, Ватанны ярату, авыл һәм дәүләт белән горурлану тәрбияләү.

Бу максатларны тормышка ашырганда түбәндәге бурычлар хәл ителә:

1.Гаилә тарихын өйрәнү.Шәҗәрәне төзү.

2.Мәктәп тарихын өйрәнү.

3.Авыл һәм район тарихын өйрәнү.

4.Эзләнү эшләре алымнарын үзләштерү.

5.Туган як тарихы буенча материаллар җыю.

6.Кешеләр арасында чыгышлар ясау күнекмәләрен булдыру.

7.Экскурсоводлар әзерләү.

8.Архив эшләре белән таныштыру.

9.Табигать белән гармониядә тору.

10.Укучыларны туган якның мәдәни һәм тарихи байлыклары белән таныштыру.

# 1 нче ел өчен якынча тематик план

| Т.б. № | Дәрес темасы | Теориянең сәгать саны | Практиканың сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Кереш | 2 | - |
| 2. | Туган як тарихын өйрәнү фәне | 4 | - |
| 3. | Минем гаилә тарихы | 4 | 8 |
| 4. | Минем урамым<br>а)Тегермәнлек урамнары<br>б)урам исемнәре ни сөйли | 4 | 8 |
| 5. | Мәктәп тарихы<br>а)мәктәп оешу<br>б)җидееллык мәктәп ачылу<br>в)урта мәктәп<br>г)мәктәп чыгарган атаклы якташлар | 8 | 12 |
| 6. | Авыл тарихы<br>а)авыл исеменең чыгышы<br>б)авыл төзелү турындагы легендалар<br>в)Казан ханлыгы руслар тарафыннан басып алынганнан соң безнең авыл<br>г)Е.Пугачев җитәкчелегендә үткән фетнә чорында авыл һәм төбәк<br>д)XIX гасырда авыл: халык саны һәм перепись<br>е)XX гасыр башында Югары Тегермәнлек<br>ж)колхоз төзелү<br>з)Бөек Ватан сугышында авылдашлар. “Хәтер” китабы<br>к)XX гасырның икенче яртысында авыл һәм колхозның үсеше | 14 | 16 |
| 7. | Мәктәп музееның эшчәнлеге<br>а)экскурсияләр үткәрү<br>б)эксурсоводлар әзерләү<br>в)иҗади проектлар | 20 | 12 |
|  | Барлыгы | 56 | 56 |

# Программа

**Кереш.** Туган як тарихын өйрәнү түгәрәгенең эшчәнлеге һәм бурычлары. Туган якны өйрәнүчеләрнең эш үзенчәлекләре. Дәресләрне оештыру. Эшнең әһәмияте. Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктаж.

**Туган як тарихын өйрәнү фәне.** Фән буларак туган як тарихын өйрәнү. Өйрәнү объектлары. Туган як тарихын өйрәнү формалары. Музей экспозицияләре һәм фонды-туган як тарихын өйрәнү чыганаклары.

Практик эш.. Туган як тарихи объектлары белән таныштыру.

**Минем гаилә тарихы.** Гаилә тарихын өйрәнү.

Практик эш.. Шәҗәрә төзү.

**Минем урамым.** Музей материаллары аша урам тарихы белән танышу. Урам исеменең килеп чыгышын аңлату. Экскурсия үткәрү.

Практик эш. Урамда яшәүче өлкән кешеләр белән очрашып истәлекләр язып алу. Һәр нигездә яшәгән кешеләрне барлау. Фотоларга төшү. Альбом төзү.

**Мәктәп тарихы.** Музей һәм архив материаллары аша туган мәктәп тарихы белән танышу. Элекке мәктәпне тәмамлаучылар белән очрашып истәлекләрен язып алу.

Практик эш. Мәктәп чыгарылышларын барлап чыгу. Укучылар исемлеген төзеп, аларның хәзерге тормышын юлын ачыклау. Альбом төзү. Мәктәп тарихын матбугатта яктырту.

**Авыл тарихы.** Мәктәп музее һәм архив материаллары аша авылның килеп чыгу тарихы, исеме, үсеше белән танышу. Туган авылның киләчәген фаразлау. Дәресләрдә матриалларны куллану.

Практик эш.  Экскурсияләр үткәрү. Авыл эчендә йөреп материаллар җыю. Изге урыннарда булу. Фото,-видеоматериаллар булдыру. Авылның күренекле кешеләре белән очрашу үткәреп, истәлекләрен язып алу.

**Мәктәп музее эшчәнлеге.** Мәктәп музее турында положение. Музей экспозицияләре. Экспонатлар тематикасы. Аннотацияләр төзү. Экспонатлар өчен паспортлар. Текстлар җыю. Музей фондлары. Музей советы.

Практик эш. Тематик – экскурсия планы төзү. Музей советы саулау. Экскурсоводлар әзерләү. Музейда дәрес үткәрү. Җыелган материалларны теркәп бару, саклау.

## **2 нче ел өчен якынча тематик план**.

| Т.б. № | Дәрес темасы | Теориянең сәгать саны | Практиканың сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Район тарихы<br>а) Балык бистәсе исеменең чыгышы<br>б)Балык бистәсе оешу тарихы<br>в)Кызыл Йолдыз районы тарихы<br>г)Районыбыздан чыккан атаклы якташлар | 18 | 14 |
| 2. | Районның тарихи-туристик мөмкинлекләре<br>а)Кашан шәһәрлеге<br>б)Чаллы шәһәрлеге<br>в)районыбызның тарихи-табигать тыюлыклары | 8 | 2 |
| 3. | Тарихи һәйкәлләр, изге урыннар<br>а)борынгы шәһәрчекләр<br>б)изге чишмәләр<br>в)Тегермәнлек авылының “Зариф бабай чишмәсе” | 6 | 6 |
| 4. | Табигатьне саклау<br>а)Туган ягым – яшел бишек<br>б)элеккеге болынлыклар<br>в)урманнар<br>г)”Чишмә” операциясе | 6 | 4 |
| 5. | Тарихи экспедициягә әзерләнү (Гигиена. Беренче медицина ярдәме. Куркынычсызлык кагыйдәләре) | 4 | - |
| 6. | Тарихи экспедиция үткәрү | 2 | 12 |
| 7. | Мәктәп музее эшчәнлеге<br>а)экскурсоводлар әзерләү<br>б)экскурсияләр оештыру<br>в)иҗади проектлар | 8 | 22 |
| | Барлыгы | 52 | 60 |

# Программа

**Район тарихы.** Музей һәм архив материаллары аша район тарихы белән таныштыру. Туган як территориясе, аның чикләре. Халкы. Милләтләр. Туган як табигате.

Практик эш. Район үзәк музеена экскурсия оештыру. Фото,-видеоматериаллар булдыру. Туган як тарихы буенча материаллар җыю. Музей өчен стенд – кулланма төзү.

**Районның тарихи-туристик мөмкинлекләре.** Районның географик һәм икъдисади характеристикасы. Географик урыны, рельефы, климаты, фаунасы һәм флорасы, табигый байлыклары, промышленность үсеше, авыл хуҗалыгы, транспорт чаралары. Экскурсия объектлары: тарихи урыннар, музейлар, предприятияләр, күмәк авыл хуҗалыклары. Бер көнлек булган поход мөмкинлекләре. Туган як буенча әдәбият.

Практик эш. Экскурсия үткәрү. Фото,-видео материаллар булдыру.

**Тарихи һәйкәлләр, изге урыннар.** Тарихи һәйкәлләр һәм изге урыннар белән таныштыру. Аларның барлыкка килү тарихын ачыклау.

Практик эш. Тарихи һәйкәлләр һәм изге урыннарга экскурсия. Фото,-видео материаллар җыю. Альбом төзү.

**Табигатьне саклау.** Табигатьне саклау һәр кешенең – изге бурычы. Табигатьне саклау турында закон. Укучыларның табигатьне саклау бурычлары.

Практик эш. Агачлар утыртуда ктнашу. Язгы табигатьне чистарту өмәләрендә катнашу. “Чишмә” операцияләре үткәрү (чишмәләрне чүптән чистартып тору)

**Тарихи экпедициягә әзерләнү.** Гигиена. Беренче медицина ярдәме күрсәтү. Куркынычсызлык кагыйдәләре. Экспедициянең максатын һәм урынын билгеләү. Группаны комплектлаштыру. Кирәк – яраклар.

Практик эш. Экспедициягә ззерләнү. Аның максатларын билгеләү. Кирәк яракларны булдыру. Укучыларның әзерлеген тикшерү, инструктаж үткәрү.

**Тарихи экспедиция үткәрү.** Туган як тарихы буенча теоретик мәгълүмат җыю. Фото,- видео материаллар булдыру. Кәндәлек алып бару.

**Мәктәп музееның эшчәнлеге.** Мәктәп музее турында положение. Музей профиле. Музей экспозициясе. Экспонатлар тематикасы. Аннотацияләр төзү. Экпонатлар өчен паспортлар төзү. Музей фонды. Экспонатларны саклау тәртибе. Экскурсияләр текстын әзерләү. Музейлар смотры. Башка музейлар белән элемтә.

Практик эш. Музей өчен материаллар җыю. Тематик-экскурсия планын төзү. Мәктәп музее фонды белән эшләү. Җыелган материалларны язмача теркәп бару. Экскурсия текстларын әзерләү. Экскурсоводларны әзерләү. Мәктәп балалары өчен экскурсия үткәрү.

## 3 ел өчен якынча тематик план

| Т.б. № | Дәрес темасы | Теориянең сәгать саны | Практиканың сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Тарихи экспедиция нәтиҗәләре | - | 4 |
| 2. | Өлкә(республика) тарихы<br>а)Идел буе Болгар дәүләте<br>б)Алтын Урда<br>в)Казан ханлыгы<br>г)Казан ханлыгының Явыз Иван тарафыннан басып алынуы<br>д)Казан крае рус дәүләте составында<br>е)Казан губернасы оештырылу<br>ж)Татарстан АССР төзелү | 20 | 14 |
| 3. | Республиканың тарихи һәйкәлләре<br>а)Болгар шәһәрләре<br>б)Казан шәһәре<br>в)изге урыннар | 8 | 6 |
| 4. | Патриотик эш.<br>а)милли –азатлык хәрәкәте<br>б)1812 елгы Ватан сугышы чорында безнең край<br>в)Бөек Ватан сугыш чорында халкыбыз батырлыгы<br>г)4 ноябрь – Халык бердәмлеге көне | 4 | 4 |
| 5. | Тарихи экспедициягә әзерләнү | 4 | - |
| 6. | Тарихи экспедиция үткәрү | 2 | 16 |
| 7. | Мәктәп музееның эшчәнлеге<br>а)экскурсияләр оештыру<br>б)иҗади проектлар | 6 | 24 |
| | Барлыгы | 44 | 68 |

# Программа

**Тарихи экспедиция нәтиҗәләре.** Түгәрәкнең практик эшен яктырту. Җыелган мәгълүматны фактлар белән чагыштыру. Белгечләр белән консультация. Мәктәп музее өчен булган материалларны урнаштыру тәртибе. Стендны ничек ясарга? Отчет. Отчет күргәзмәсе. Балалар арасында экспедиция пропагандасы алып бару, шуның аша түгәрәккә яңа укучыларны тарту.

Практик эш. Экспедиция нәтиҗәләрен чыгару. Стенд һәм альбомнар төзү. Мәктәп һәм музей өчен күргәзмә әсбаплар ясау. Нәтиҗәләр буенча күргәзмә оештыру, кичә үткәрү. Отчет ясау.

**Өлкә(республика) тарихы.** Туган республика тарихы. Борынгы заман чоры. Идел буе Болгар дәүләте. Алтын Урда. Казан ханлыгы. Россия дәүләте составында. Губерна төзелү. Халык санын алулар. Е.Пугачев җитәкчелегендәге фетнә. Ватан сугышы чорында туган як. Крестьян реформасы. Гражданнар сугышы. НЭП. Коллективлаштыру. Бөек Ватан сугышы чорында туган як. Туган ягым мәдәнияте.

Практик эш. Мәктәп музее өчен тарихи материаллар җыю. Күренекле кешеләр белән очрашу.

**Республиканың тарихи һәйкәлләре.** Туган якның тарихи һәйкәлләрен саклау бурычы. Һәйкәлләрнең төрләре: археологик, тарихи, документаль( хакимият актлары, архив документлары, борынгы язмалар, фольклор, музыка ). Изге урыннар( чишмәләр, каберлекләр).

Практик эш. Тарихи һәйкәлләр буенча материаллар җыю( документлар, фотолар, халык иҗаты).

**Патриотик эш.** Тәрбия бирүдә патриотизмның роле. Халкыбызның чит илбасарларына каршы көрәше. Бөек Ватан сугышы геройлары-безнең якташлар. Сугыш ветераннары белән очрашу. “Хәтер көне”.

Практик эш. Бөек Ватан сугышы буенча материаллар җыю. Ветераннар белән очрашып истәлекләрен язып алу. Фотога һәм видеокамерага төшерү.
Республиканың “Хәтер” китабы белән эшләү, аны бастыруда катнашу. Сугыш ветеранарына багышлап альбомнар һәм стендлар төзү. Хәзерге чорда армиядә булып кайтканнар белән очрашу үткәрү.

**Тарихи экспидициягә әзерләнү.** Гигиена таләпләре. Беренче медицина ярдәме. Инструкция. Маршрутны билгеләү. Группаны комплектлаштыру. Кирәк-ярак. Документларны тутыру. Көндәлек эш. Максат һәм бурычлар.

Практик эш. Походка әзерләнү. Аның максат һәм бурычларын билгеләү. Схема төзү. Укучыларның белемнәрен һәм күнекмәләрен тикшерү.

**Тарихи экспедиция үткәрү.** Көндәлек алып бару. Туган як тарихы буенча теоретик һәм матди материаллар җыю. Табигать белән танышу. Билгеләнгән территориянең үзенчәлекләрен ачыклау. Мөмкин булган күренекле кешеләр белән очрашу.

**Мәктәп музееның эшчәнлеге.** Мәктәп музее турында положение. Музей профиле. Музей экспозициясе. Экспонатлар тематикасы. Аннотацияләр төзү.

Экспонатлар өчен паспортлар төзү. Текстлар төзү. Экспонатларны саклау тәртибе. Музейда дәрес үткәрү. Смотрлар. Башка музейлар белән элемтә.

Практик эш. Мәктәп музее өчен материаллар җыю. Тематик – экскурсия планы төзү. Музей фонды белән эш. Материалларны исәпкә алып бару, саклау. Экскурсия текстларын төзү. Экскурсоводлар әзерләү. Күргәзмәләр оештыру. Экскурсияләр үткәрү.

## Мәктәп музеенда үткәрелә торган экскурсияләр тематикасы:

1.Матросовчы якташыбыз Барый Шәвәлиев
2.Бөек Ватан сугышында безнең авылдашлар
3.Бөек Ватан сугышы чорында безнең авыл
4.Авылым тарихы
5.Габдулла Тукай исемендәге күмәк хуҗалык тарихы
6.Мәктәп тарихы
7.Музей оешу тарихы
8.Батырлык эзләреннән ( сугыш булган урыннарда булып кайткан истәлекләр )
9.Әфганистан – йөрәк ярасы
10.Матросовчылар
11.”Чәчәкләр сөйли белә” (Барый Шавалиев турында китап буенча )
12.Сугыш чоры балалары
13.Хезмәт ветераннары
14.Атаклы авылдашларыбыз
15.Музей советы эшчәнлеге тарихы
16.”Хәтер” китабы
17.Муса Җәлил һәм җәлилчеләр

## Методик яктан тәэмин ителеш.

1 нче ел өчен.

**Кереш һәм туган як тарихын өйрәнү фәне** темаларын үткән вакытта укучыларга лекция һәм музей буенча экскурсия үткәрелә.Укучылар эзтабарлык эшенә беренче тапкыр аяк баскан вакытта, шулай ук элеккеге елларда түгәрәк эшен яктырткан видео-язмаларны да кулланырга мөмкин. Алдан төзелгән фото-альбомнар да укучыларга ярдәм итәр.

**Гаилә тарихы**н өйрәнгән дәресләрдә укучылар укытучы җитәкчелегендә күбрәк иҗади эшлиләр. Һәрбер түгәрәккә йөрүче үзенең шәҗәрәсен төзи. Нәсел агачы компьюторда җыела алган кебек, кулдан да матурлап төрле формада урнаштырыла ала.

Эзтабарлар үзләренең **урамнарын өйрәнгәннән** соң кечкенә генә конференция сыман эзләнү чарасы үткәрергә мөмкин.

**Мәктәп тарихын** барлаганда ветеран укытучылар белә очрашулар оештырырга була.

**Авыл тарихы**н өйрәнгәндә күбрәк җитәкче тарафыннан сөйләм теле белән һәм язма рәвештә мәгълүмат бирелә. Бу тема өйрәнелүнең нәтиҗәсе итеп кечкенә генә авыл тарихын тасвирлаган китапчык төзү булыр.

**Мәктәп музее эшчәнлеге**нең беренче дәресләрендә, әлбәттә укучылар өчен җитәкче тарафыннан музей эшчәнлегенең тарихы турында экскурсия үткәрергә кирәк. Шул ук вакытта аларның нәрсә белән күбрәк кызыксынганлыгын белү ниятеннән әңгәмә үткәрү зарури. Киләчәктә экскурсияләр тематикасын бүлгәндә бу бигрәк тә кирәк булачак. Беренче елда ук үз темасы буенча укучы экскурсия планын төзи һәм аның эчтәлеген булдыра.

Беренче ел шөгыльләнгәндә түбәндәге материалларны һәм техник чараларны кулланырга мөмкин:

-- проектор;
--фотоаппарат;
--магнитофон;
--телевизор һәм видеомагнитофон;
--интернеттан файдалану һәм документларны язу өчен компьютер;
--папкалар, фотоальбомнар һәм канцелярия кирәк-яраклары;
--китаплар фонды.

## 2 нче ел өчен

**Район тарихы**н өйрәнгән вакытта атаклы якташлар белән очрашу формасы бик тә уңышлы булыр. Район үзәк музеена экскурсия балаларга тулырак информация бирәчәк. Тарих атналыгы вакытында туган якка багышланган кичә үткәрергә була. 5-11 сыйныф укучыларына оештырылган ( моны әлбәттә түгәрәккә йөрүчеләр оештыра ) бу чарада туган як тарихына багышланган викторина-уеннар зур урын алырга тиеш. Мондый вариантта мөмкин: ата-аналар һәм аларның балалары ике командага бүленеп ярышалар һ.б. Бу кичә буенча фото-отчет төзергә һәм матбугатта яктыртырга була.

**Районның тарихи-туристик мөмкинлекләре**н өйрәнгән вакытта күп рольне укытучының сөйләп аңлатуы тора.

**Тарихи һәм изге урыннар**ны барлаганда авылдан ерак булмаган изге урыннарга җәяүле сәяхәт кылырга була. Булган урыннарны фотога төшереп, мәктәп укучылары өчен фото-күргәзмә оештыру эшчәнлек нәтиҗәсе булып тора.

**Табигатьне саклау** – изге бурыч икәнлеген балаларга сеңдерү җитәкченең бурычы. Шуңа күрә дә укытучы бу теманы өйрәнгәндә кул астында булган материалларны файдаланып әңгәмә үткәрергә тиеш. Агачлар утыртуда һәм чишмәләрне чистартуда катнашу, анда укучыларның нинди дәрәҗәдә тырышлык белән катнашуы җитәкчедә нинди дә булса нәтиҗә чыгарырга этәрә.

**Тарихи экспедициягә әзерләнү** вакытында медицина вәкилен чакыртып аңлатма бирергә кирәкле. ОБЖ укытучысы да түгәрәк җитәкчесенә ярдәмгә килә ала.Тарихи экспедициягә барыр алдыннан маршрутны сайларга кирәк. Бу чара алдыннан ата-аналар белән дә әңгәмә үткәрергә кирәктер минемчә.

**Тарихи экспедиция** барышында көндәлек алып барыла. Фото-видео мәгълүмат җыелып мәктәптә үткән кайбер тәрбияви чараларда кулланыла.

**Мәктәп музееның эшчәнлеге**нең күп өлеше алдагы елдагыга караганда үзгәрәк практик якка күбрәк игътибар биреләчәк.Укучылар мөстакыйль рәвештә башлангыч сыйныф укучыларына экскурсия үткәрәләр.

Икенче ел шөгыльләнгәндә түбәндәге материалларны һәм техник чараларны кулланырга мөмкин:

--фотоаппарат;
--магнитофон
--интернеттан файдалану һәм документларны язу өчен компьютер;
--видеокамера;
--папкалар, фотоальбомнар һәм канцелярия кирәк-яраклары;
--китаплар фонды

# 3 нче ел өчен

**Тарихи экспедициясенә нәтиҗә** чыгарганда фото-альбом төзелә . Шулай ук район матбугатында яктырту уңай күренеш булачак.

**Өлкә ( республика ) тарихы**н өйрәнгән дәресләрдә укучылар җитәкче белән янәшә тигез күләмдә материалны өйрәнә. Библиотека фонды бу очракта зур урын алып тора. Мөмкин булган очракта архив материалларын куллану уңышлы булыр. Беренче дәресләрдә балаларга викторина сораулары бирелергә мөмкин. Мөстакыйль эзләнү эшләре вакытында җаваплар табып уен формасында чара үткәрелә.

**Республиканың тарихи һәйкәлләре**н өйрәнгәндә матбугат язмалары, матур һәм өстәмә әдәбият материаллары буенча түгәрәк өстәл артында әңгәмәләр оештырырга була. Тарихи һәйкәлләрне ничек сакларга дигән проблемалы сорауга җавап эзләнелә.

**Патриотик эш** вакытында сугыш һәм хезмәт ветераннары белән мәктәптә, аларның өйләрендә очрашулар тәрбия бирүдә зур роль уйный. Аларның истәлекләрен язып алу киләчәк өчен кирәклеген аңлату эзтабарларга аңлату җитәкченең бурычы. Яңа кертелгән – Халык бердәмлеге көнен билгеләп үткән вакытта калган укучыларга аңлатканда түгәрәккә йөрүчеләр укытучының уң кулына әверелергә мөмкин.

**Тарихи экспедиция әзерләнү** узган елдагы формада үткәреләчәк.

Ә **тарихи экспедиция** үзе, еракка булган маршрут буенча үткәрелә. Узган ел район эчендә булган бу чара, 3 елда республика күләмендә үткәрелә ала. Экспедиция барышында балаларга экскурсия үткәрелә, алар үзлектән дә тирә-якны өйрәнеп материал җыелар, көндәлек тутыралар. Кире кайтуга ук отчет төзелеп күргәзмә оештырыла, матбугатта яктыртыла.

**Мәктәп музееның эшчәнлеге** белән тулысынча диярлек укучылар тарафыннан төзелгән музей советы тарафыннан мөстакыйль рәвештә алып бара. Җитәкче бу очракта юл күрсәтүче ролен үти. Төрле конкурсларда катнашу зур урын алып тора, төп иҗади эш итеп санала.

Өченче ел шөгыльләнгәндә түбәндәге материалларны һәм техник чараларны кулланырга мөмкин:

--фотоаппарат;
--магнитофон;
--интернеттан файдалану һәм документларны язу өчен компьютер;
--видеокамера;
--папкалар, фотоальбомнар һәм канцелярия кирәк-яраклары;
--китаплар фонды.

## Чыганаклар:

1.Ашуров В.Н. и др. Историческое краеведение.-М.,1980
2.Кружковая работа по истории и обществознанию.-М.,1984
3.Матюшин Г.Н. Историческое краеведение.-М.,1987
4.Методика историко-краеведческой работы в школе.-М.,1982
5.Просстов М.П. Кружковая работа(сборник статей). М.,1984
6.Сейненский А.Е. Родной край : страницы истории. В помощь педагогу-краеведу. Преподование истории в школе. 1995.№ 4. С.61
7.Демин М.А. Научно-образовательный центр исторического краеведения.
8.Элькин Г.Ю., Огрызко З.А. Школьный музей. – М., 1972
9. Фокеева И.М. Национально-региональный компонент исторического образования.-Казань,2003